**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Саклаубаш авыл җирлегенең Саклаубаш торак пунктында
2023 елда үзара салым кертү турында

**2022 нче елның 18 нче ноябре** **№ 4**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлегенең Саклаубаш авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге Саклаубаш авылы территориясендә I төркем инвалидлардан; хәрби хезмәт үтүчеләрдән; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча Саклаубаш авылында теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өсен түбәндәге эшләрне башкарырга җибәрергә:
- элмә такталар һәм аншлагларны буяу өчен буяу сатып алу:
-МТЗ-82.1 махсус техникасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запчастьләр сатып алу, машина йөртүчегә хезмәт хакы түләү);
- генераторга һәм триммерга бензин сатып алу;
- Халыкара хатын-кызлар көне, Җиңү көне, сабантуй, өлкәннәр көне, Инвалидлар көне, Саклаубаш авылында мәдәни чаралар өчен Бүләкләр, Бүләкләр алу;
- материаллар сатып алып су башнясын койма белән әйләндереп алу.
- “Сарман” газетасында некрологлар бастырып чыгару
- Д.Сөләйманов урамына вак таш сатып алып юл салу.
- Зияратка генератор һәм перфоратор сатып алу.
- Ленин урамындагы тыкырыкка шлагбаум сатып алып урнаштыру.

3. Әлеге карарны Саклаубаш авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Саклаубаш авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Л.М.Габидуллина